ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 02.02.2024 141 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2023 елның 26 декабрендәге 2104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бүлегенең социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы исемен норматив хокукый актларда үзгәртү кирәклеге турындагы 2024 елның 16 гыйнварындагы ЭВ-09-25/3433 номерлы хаты буенча Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошинның 2024 елның 18 гыйнварындагы 1703-АП номерлы боерыгын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2023 елның 26 декабрендәге 2104 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны куллану аша әлеге карар һәм бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаның операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ташламалар бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Җитәкче Р.Э. Әхмә